ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

19.12.2024

г.Казань

**КАРАР**

№ 663-109/тэ-2024

Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясе өчен 2025-2029 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2024 ел, №36-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» АҖ) тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2029 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы

Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2024 № 663-109/тэ-2024
карарына кушымта

## Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» АҖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2025-2029 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 027,19 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 1 223,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 1 223,18 | | | | | |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 1 272,04 | | | | | |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 1 272,04 | | | | | |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 322,92 | | | | | |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 1 322,92 | | | | | |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 1 375,84 | | | | | |
| | | 01.01.2029 башлап 30.06.2029 кадәр | 1 375,84 | | | | | |
| | | 01.07.2029 башлап 31.12.2029 кадәр | 1 430,87 | | | | | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге